КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 июль г.Казань № 561

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 6 июль, 561 нче
карары белән расланды

# Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына Министрлыкка бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертлар җирле үзидарә органнары вәкаләтләре нигезендә түбәндәге максатлар өчен бирелә: социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү, техник җиһазландыру, җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне һәм су чыгаруны оештыру, капиталь ремонтлау һәм демонтажлау; социаль әһәмиятле объектларны төзекләндерү һәм ремонтлау; тышкы төзекләндерү объектларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән авария хәлендәге торак йортларны сүтүне гамәлгә ашыру өлешендә; скульптуралар ясау (сатып алу) һәм урнаштыру; проект һәм тикшерену эшләрен башкару өлешендә проектларны тормышка ашыру; күпфатирлы йортларда урнашкан торак булмаган биналарның базар бәясен билгеләүне үткәрү; коммуналь техника сатып алу һәм аны ремонтлау (капиталь ремонтлау) (алга таба – төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чаралар).

6. Муниципаль берәмлекләргә башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары түбәндәгеләр була:

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә

барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен билгели торган муниципаль хокукый актлар булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

Министрлык белән бу Тәртипнең 11 нче пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар (алга таба – килешү) бирү турында килешү төзү.

7. Хуҗалыкның башка бюджетара трансфертларыннан файдалану нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

а) социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, техник җиһазландыруга, җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне һәм су чыгаруны оештыруга, социаль әһәмиятле объектларны төзекләндерүгә һәм ремонтлауга карата – расланган проект документациясе нигезендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү, техник җиһазландыру, җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне һәм су чыгаруны оештыру, социаль әһәмиятле объектларны төзекләндерү һәм ремонтлау барышында кулланыла торган төзелеш материаллары һәм эшләр башкару;

б) тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга карата – тышкы төзекләндерү объектларын (объектлары элементларын) төзү, карап тоту һәм төзекләндерү эшләрен башкару;

в) авария хәлендәге торак йортларны сүтүне гамәлгә ашыруга карата – сүтелгән авария хәлендәге торак йортлар саны;

г) скульптуралар ясау (сатып алу) һәм урнаштыруга карата – ясалган (сатып алынган) һәм урнаштырылган скульптуралар саны;

д) проект һәм тикшерену эшләрен башкару өлешендә проектларны тормышка ашыруга карата – башкарылган проектлар саны;

е) күпфатирлы йортларда урнашкан торак булмаган урыннарның базар бәясен билгеләүне үткәрүгә карата – күпфатирлы йортларда урнашкан, бәясе билгеләнгән торак булмаган биналар саны;

ж) коммуналь техника сатып алуга һәм аны ремонтлауга (капиталь ремонтлауга) карата – сатып алынган һәм ремонтланган техника саны.

8. Башка бюджетара трансфертларны алу өчен муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары Министрлыкка башка бюджетара трансфертлар бирү өчен ирекле рәвештә язылган заявка кертә.

9. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чаралар буенча муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның гомуми күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = \sum P_i,$$

монда $P_i$ – төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чараларны үткәрү өчен түбәндәгеләргә карата исәпләп чыгарылган чыгымнар:

а) социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, техник җиһазландыруга, җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне һәм су чыгаруны оештыруга, капиталь ремаонтлауга һәм демонтажлауга, социаль әһәмиятле объектларны төзекләндерүгә һәм ремонтлауга, скульптуралар ясауга (сатып алуга) һәм урнаштыруга карата смета документларындагы тиешле исәп-хисаплар, гамәлдәге смета нормативлары, эшләрнең физик күләмнәре, проект документлары белән күздә тотылган конструктив, оештыру-технологик һәм башка хәл итүләр нигезендә;

б) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, 117 нче карары белән расланган нормативлар нигезендә тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга карата;

в) түбәндәге формула буенча авария хәлендәге торак йортларны сүтүне гамәлгә ашыруга карата:

$$P_i = N \times K,$$

монда:

N – сүтелергә тиешле йортлар саны;

K – бер күпфатирлы йортны сүтү кыйммәте коммерция тәкъдимнәрен (подрядчы оешмаларның коммерция тәкъдимнәрен җыю) мониторинглау нәтиҗәләре буенча тәкъдимнең иң түбән бәясе буларак билгеләнә;

г) Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының «Төзелештә проект эшләренә база бәяләре белешмәлекләрен куллану буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2009 елның 29 декабрендәге 620 номерлы боерыгы белән расланган Төзелештә проект эшләренә база бәяләре белешмәлекләрен куллану буенча методик күрсәтмәләр нигезендә проект һәм тикшеренү эшләрен башкару өлешендә проектларны тормышка ашыруга карата;

д) күпфатирлы йортларда урнашкан торак булмаган урыннарга базар бәясен билгеләүне үткәрүгә карата түбәндәге формула кулланыла:

$$P_i = N \times S,$$

монда:

N – бәяләнергә тиешле урыннар саны;

S – бәяләү кыйммәте коммерция бәяләре (эксперт оешмаларының коммерция тәкъдимнәрен җыю) мониторингы нәтиҗәләре буенча тәкъдимнең иң түбән бәясе буларак билгеләнә;

е) коммуналь техника сатып алуга һәм аны ремонтлауга (капиталь ремонтлауга) карата түбәндәге формула кулланыла:

$$P_i = \sum N_k \times S_k,$$

монда:

$N_k$ – коммуналь техниканың k тибындагы саны;

$S_k$ – коммуналь техниканың k тибындагы бәясе (ремонт кыйммәте) коммерция бәяләре мониторингы нәтиҗәләре буенча тәкъдимнең иң түбән бәясе буларак билгеләнә.

10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан расланган форма буенча килешү нигезендә бирелә.

11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең мәгънәсе;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының муниципаль берәмлек тарафыннан үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы.

12. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең килешү белән билгеләнгән һәм фактта ирешелгән мәгънәләрен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы белән операцияне исәпкә алу өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетларына күчерелә.

14. Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары Министрлыкка башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм килешүдә каралган вакытларда һәм формада башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыра.

15. Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары һәм вазыйфаи затлар тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларны бирү шартларының үтәлеше өчен законнар нигезендә җавап бирә.

16. Бу Тәртип нигезендә алынган, агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Министрлыкның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу

турындагы карары нигезендә акча әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдә агымдагы финанс елында әлеге башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килә торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен алар элегрәк бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты керемен кире кайтарылырга мөмкин.

Бу Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемен кучерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемен, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

17. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

18. Муниципаль берәмлек тарафыннан нәтиҗәнең мәгънәсенә килешү белән билгеләнгән вакытларда ирешелмәгән очракта, муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{\text{кире кайтару}} = V_{\text{мбт}} \times k \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{\text{мбт}}$ – муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

k – башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

Муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен исәпләп чыгарганда хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендә ($V_{\text{мбт}}$) башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше исәпкә алынмый.

Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты (k) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – башка бюджетара трансфертларны файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертларны файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең план буенча күрсәткече.

19. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары килешүдә һәм бу Тәртиптә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.